# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Рус Әҗиле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

29 ноябрь 2021 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә шушы сорау буенча 15 сәгать 00 минутта 2021 елның 29 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Рус Әҗиле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, I группа инвалидларыннан тыш, 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?

**- Рус Әҗиле авылында балалар мәйданчыгы төз ;**

**- смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;**

«ӘЙЕ» « КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **76** кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә **48** кеше катнашты, бу **63,15** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда **48** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Рус Әҗиле авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым акчаларын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә Рус Әҗиле авылында даими яшәүче һәр балигъ булган, I группа инвалидларыннан тыш 500,00 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

**- Рус Әҗиле авылында балалар мәйданчыгы төз ;**

**- смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру;**

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Яшел Үзән муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче Г.Ф.Семахина